**Каралды**
**Методик берләшмә җитәкчесе**
**______ Рамазанова Р.Н.**
**Беркетмә № 1**
**25 нче август 2017 нче ел**

**Килешенде**
**Уку-укыту эшләре буенча**
**директор урынбасары**
**______ Г.Т.Исмагилова**
**28 нче август 2017 нче ел**

**Раслыйм**
**Мәктәп директоры**
**________ Г.Т.Сабирзянова**
**Приказ № 71**
**28 нче август 2017 нче ел**

**Татарстан Республикасы**

**Сарман муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**

**“Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе” татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Хатыйпова Гөлназ Рафис кызының**

**8 нче сыйныф өчен татар теленнән**

**ЭШ ПРОГРАММАСЫ**

**Педсовет утырышында каралды**
**Беркетмә№ 1 28 нче август 2017 нче ел**

**2017-2018 нче уку елы**

# АННОТАЦИЯ

Дәүләт стандартларына туры китерелеп 8 нче сыйныфта татар теле дәресләренә эш программасы түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1.”Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы(2004нче ел, 1нче июль)
2. "2004-2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы” (2004нче ел, 11нче октябрь).
3. Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законы (2007 ел, 1 декабрь).
4. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы (“Закон об образовании” Закон Российской Федерации)
5. Гомуми белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумы (ТР Мәгариф министрлыгының 478 номерлы боерыгы, 05.07.2000 ел).
6. ”Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа ” 5-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010нчы ел.
Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы. – Казан, 2008.

**Дәреслек:** Зәкиев М.З. , Максимов Н.В. Татар теле: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы 8нче сыйныф. Казан, “Татарстан китап нәшрияты”, 2015.

**Сыйныф:** *8*

**Укытучы: Хатыйпова Гөлназ Рафис кызы**

**Сәгатьләр саны:**

**Барлыгы:** *105 сәг.; атнага 3 сәг.*

**Бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләре** *31*

***Планлаштыру*** *"Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа " 5-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, "Мәгариф" нәшрияты, 2010 нчы ел.*

**Дәреслек**: *Зәкиев М.З. , Максимов Н.В. Татар теле: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы 8нче сыйныф. Казан, "Татарстан китап нәшрияты", 2015.*

# АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Программа Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законына (2007 нче ел, 1 нче декабрь),”Татар телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа”га (5-11 нче сыйныфлар), МБББУ“Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең эш программасы турында нигезләмәсенә, МБББУ “Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе” нең 2017-2018 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.

**Эш программасы түбәндәге норматив документлар нигезендә төзелде:**

- “Россия ФедерациясендәМәгариф турында” Федераль Законы (29.12.2012г.)
- “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы, 2013 ел.
- “Сарман урта гомумбелем бирү” мәктәбенең “Укыту курсы һәм предметының эш программаларын раслау һәм эшләү тәртибе структурасы” турындагы нигезләмәсе
- Сарман муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “ Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең 2017-2018 нче уку елына укыту планы
- Татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы. – Казан, 2008.
- ”Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теленнән программа ” 5-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010 нчы ел.

Укыту планында 8 нче сыйныфта татар телен өйрәнүгә атнага 3 сәгать вакыт бирелә. Татар теленнән эш программасы “Татар урта гомуми белем мәктәпләре өчен татар теленнән программа”га (М.З.Зәкиев, С.М. Ибраһимов, Н.В.Максимов. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010) нигезләнеп, белем бирү учреждениесенең фәннәрне тирәнтен өйрәнү юнәлешле булуын искә алып төзелде.

Программа материалы 105 сәгатьлек булып, атнага 3 сәгать укыту хисабыннан төзелде. Якынча программада туры һәм кыек сөйләм темасына 12 сәгать каралган. Диктант һәм хаталарны төзәтү эше өчен шул темадан 2 сәгать алдым. Кайбер темалар бәйрәм көннәренә туры килү сәбәпле , дәресләр кушылды һәм темаларны үзләштерү мөстәкыйль рәвештә өйрәнүгә бирелде.

Татар теленнән дәүләт стандартында (Казан, 2004) синтетик һәм аналитик иярченле кушма җөмлә темасы каралган. Ә якынча программада бу темага аерым сәгать бирелмәгән. “Иярченле кушма җөмлә” темасында кабатлау өчен бирелгән 6 сәгатьне: 1)синтетик иярчен җөмләләр, 2) синтетик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре; 3)аналитик иярчен җөмләләр, 4)аналитик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре; 5)аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне кабатлау, 6)иярченле кушма җөмләләр синонимлыгы темалары өчен алдым.

“Катлаулы төзелмәләр” бүлегендә, иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау өчен, 8сәгать каралган. Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау өчен, 4сәгатьне иярченле кушма җөмләләрне йомгаклаганда, калган 4 сәгатьне “Катлаулы төзелмәләр” бүлегендә алынды.

Якынча программаның бәйләнешле сөйләм үстерү бүлегендә бирелгән 12 сәгать эчендә “Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре” темасы да каралган. Бу теманы иярченле кушма җөмләләрдә(№37) һәм катлаулы төзелмәләрдә(№-№61,68,69,70, 72,74,76,89,101) тыныш билгеләренең куелышын аңлатып бардым.

Соңгы елларда республикада татар теленең куллану даирәсе киңәйде, иҗтимагый функциясе көчәйде. Милләтара мөнәсәбәтләрне якынлаштыручы, җайга салучы чара буларак та аның мөмкинлекләре үсте. Укучыларда **лингвистик** (тел), **аралашу** (коммуникатив), **этнокультура өлкәсенә караган** (культурологик) **компетенцияләр** булдыру татар теленә өйрәтүнең максатын тәшкил итә.

**Лингвистик компетенция** (укуыларның ана телелннән мәгълүматлылыгы) фонемалар, морфемалар, сүз ясалышы, сүзтезмәләр, җөмләләр, җөмлә кисәкләре, лексик һәм грамматик берәмлекләр, лингвистик анализны һ.б. үз эченә ала.

**Аралашу** (коммуникатив) **компетенциясе** ул – башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы; хәзерге татар теле нормаларына ия булу, сүз байлыгын, сөйләмнең грамматик ягын дөрес итеп үзләштерү; телдән һәм язма формада бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен булдыру һ.б.

**Этнокультура өлкәсенә караган** (культурологик) **компетенция,** ягъни телне милли-мәдәни яссылыкта үзләштерү ул – укучыларны сөйләмгә милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен белү, татар сөйләм этикетына ия булу.

## Татар телен укытуның максатлары

- Укучыларда туган телгә хөрмәт тәрбияләү, аның иң зур рухи кыйммәт булуын аңлату.
- Укучыларның сөйләү һәм фикерләү сәләтен үстерү, татар телен тормышның төрле өлкәләрендә иркен куллана алырлык шәхесләр итеп тәрбияләү.
- Кушма җөмлә эчендәге гади җөмләләрне аера белү; диалог, монологтан файдалана белү, тыныш билгеләрен дөрес кую кунекмәләре булдыру. Татар теле, аның төзелеше, кулланылышы турында мәгълүмат бирү; сүз байлыгын арттыру; туры һәм кыек сөйләмле, кушма җөмлә һәм катлаулы төзелмә, алар янында тыныш билгеләре куелышының нормаларын һәм мөмкинлекләрен аңлату, тиешенчә куллана белү күнекмәләре фомалаштыру.
- Сөйләм культурасын тәрбияләү.

## Татар мәктәпләрендә татар теле укытуның төп бурычлары

1. Татар теленең туры һәм кыек сөйләм, кушма җөмлә һәм катлаулы төзелмә, пунктуация бүлекләре буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү.
2. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.
3. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү, татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.
4. Татар телен башка фәннәр буенча белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләре булдыру.
5. Укучыларның логик фикеләү сәләтләрен үстерү.
6. Дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү.

Укучыларның гомуми грамоталылыгын тикшерү һәм үстерү өчен, төрле характердагы диктантлар, шулай ук сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, логик фикерләү дәрәҗәсен камилләштерү максатыннан сочинение һәм изложениеләр яздырыла.

Эш программасы тел белеме тармаклары арасында системалылык һәм эзлеклелек, фәннилек, аңлаешлылык принципларын истә тотып төзелде.

**Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы коммуникатив компетенция.**

Сөйләм. Телдән һәм язма сөйләм. Диалогик һәм монологик сөйләм. Сөйләм стильләре. Матур әдәбият теле. Телдән һәм язма сөйләмне аеру. Тел берәмлекләрен, аралашуны ситуация үзенчәлекләренә карап сайлый белү. Аралашу өлкәсенә һәм ситуациясенә бәйле рәвештә телдән һәм язма сөйләмне дөрес файдалану.

Текстның темасы, төп фикере һәм төзелеше. Аларның стильләрендә жанр төрлелеге.

Татар әдәби теле һәм нормалары турында төшенчә.

Төрле язма эшләр башкару.

**Лингвистик компетенция.**

Телнең кеше тормышындагы һәм җәмгыятьтә тоткан урыны. Татар теле – ТР дәүләт теле. Татар теле – татар халкының милли теле. Әдәби тел һәм аның нормалары турында төшенчә. Татар теленең үсештә булуы. Структур һәм функциональ усеш. Тел белеменә караган сүзлекләр һәм алардан файдалану.

**Эш программасының эчтәлеге**

Тематик план, программа материалын 105 сәгатькә бүлеп, атнага 3 сәгать хисабыннан төзелде

| № | Төп темалар | Сәгать | Белем һәм күнекмәләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Тел һәм тел гыйлеме. | 1 | Тел гыйлеменең бүлекләрен искә төшерү |
| 2. | Үткәннәрне искә төшерү. Кабатлау. | 3 | Фонетика, морфология бүлеген кабатлау. |
| 3. | Диалог һәм монолог, туры һәм кыек сөйләм. Туры сөйләм, кыек сөйләм. | 9 | Диалог, реплика, туры сөйләм, кыек сөйләм, цитата төшенчәләрен аңлата белү. |
| 4. | Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. Тезмә | 6 | Тезмә кушма җөмләләрне аера белү, синтаксик анализ ясау |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, аларда бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре. | | |
| 5. | Иярченле кушма җөмлә. Төзелеше буенча синтетик, аналитик иярчен җөмлә, аларда бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре.<br>Иярченле кушма җөмләләр синонимлыгы<br>Иярчен җөмлә һәм аның мәгънә ягыннан төрләре | 22 | Иярченле кушма җөмләләрне аера белү, синтаксик анализ ясау |
| | Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау. | 4 | Иярченле кушма җөмләләрне аера белү, синтаксик анализ ясау |
| 6. | Катлаулы төзелмәләр. Катлаулы кушма җөмлә. Күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә. Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә. Тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы | 16 | Катлаулы төзелмәләрне аңлата, схемаларын ясый белү |
| | Катлаулы төзелмәләрне кабатлау, синтаксик анализ ясау | 6 | Катлаулы төзелмәләрне аера белү, синтаксик анализ ясау |
| 7. | Тезем. | 2 | Теземне таный белү, синтаксик анализ ясау. |
| 8. | Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре | 2 | Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләренең куелышы |
| 9. | Язма эшләр. Диктантлар. | 31 | |
| 10. | Барлыгы | 105 | |

# Тематик планлаштыру

Тел һәм тел гыйлеме. -1с.

Үткәннәрне искә төшерү. Фонетика, орфоэпия, орфография, графика, лексикология, фразеология, морфология бүлеген кабатлау. Гади җөмлә синтаксисын кабатлау.-3с.

Диалог һәм монолог.-2с.
Туры һәм кыек сөйләм.-1с.
Алар янында тыныш билгеләре.-2с.
Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү.-2с.
Туры сөйләмле җөмләгә синтаксик анализ ясау. турында гомуми мәгълүмат.-2с.
Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә.-2с.

Тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә, аларда бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре.-4с.

Иярченле кушма җөмлә.-1с.

Төзелеше буенча синтетик, аналитик иярчен җөмлә, аларда бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре.-4с.

Иярченле кушма җөмләләр синонимлыгы-1с.

Аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне кабатлау.-1с.

Иярчен җөмлә һәм аның мәгънә ягыннан төрләре.-1с.

Иярчен ия һәм хәбәр җөмләләр Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау.-2с.

Иярчен тәмамлык һәм аергыч җөмләләр. Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау-.2с.

Иярчен вакыт һәм урын җөмләләр. Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау. -2с.

Иярчен рәвеш һәм күләм җөмләләр Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау..-2с.

Иярчен сәбәп һәм максат җөмләләр Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау..-2с.

Иярчен шарт һәм кире җөмләләр Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау..-2с.

Иярчен аныклагыч җөмләләр. Аларның синтетик һәм аналитик төрләре, бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре; аларга синтаксик анализ ясау.-2с.

Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау -4с.

Катлаулы төзелмәләртурында төшенчә.-1с.

Күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә.-1с.

Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә. -1с.

Тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.-1с.

Тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.- 2с.

Бер-бер артлы иярүле күп иярченле кушма җөмлә.-2с.

Берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.-2с.

Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау.-4с.

Катнаш кушма җөмлә.-6с.

Катлаулы төзелмәләрне кабатлау,синтаксик анализ ясау.Аларда бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре. -6с.

Тезем.Теземнең үзенчәлекләре: санау йомгаклау бүлекләре, интонацион үзенчәлекләре, тыныш билгеләре.-2с.

Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре-2с.

Язма эшләр. Диктант. Изложение. Сочинение. Эш кәгазе. Сочинение, изложениене тикшерү, анализлау.-31с.

Искәрмә. „Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе”муниципаль белем бирү учреждениесенең „Укыту курслары һәм предметларыннан эш программалары төзелеше, аларны эшләү тәртибе турында” гы 29 нчы август 20176 нчы елда педсоветта каралган (беркетмә № 1) һәм мәктәп

директоры тарафыннан 2016 нчы елның 29 нчы августында чыккан 109 нчы санлы приказы белән расланган нигезнамәнең 5 нче пунктына таянып , дәресләр бөйрәм көнннәренә туры килү сәбәпле, 8 нче А сыйныфында дәресләр сәгатьләрне берләштерү исәбенә үтәлә.

**Календарь-тематик план**

| | **Дәреснең темасы, эчтәлеге** | **Эшчәнлек төре** | **Үтәлеш** | |
|---|---|---|---|---|
| | | | **План** | **Факт** |
| 1 | Тел һәм тел гыйлеме. Кереш. | Тел гыйлеменең бүлекләрен искә төшерү. Аларның нәрсә өйрәнүләрен кабатлау. | 04.09 | |
| 2 | Үткәннәрне искә төшерү. | Фонетика, морфология бүлеген кабатлау. | 06.09 | |
| 3-4 | Үткәннәрне кабатлау. | Гади җөмлә синтаксисын кабатлау | 08.09<br>11.09 | |
| 5 | Диктант”Күз”(кереш диктант) | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 13.09 | |
| 6 | Язма эштәге хаталарны төзәтү эше. | Хаталарны төзәтү, аларны булдырмау максатында | 15.09 | |
| 7-8 | Диалог һәм монолог | Ике яки берничә кешенең үзара сөйләшүе диалог дип аталу. Аерым кешеләрнең диалог эчендәге сүзләренең реплика дип йөртелүе. | 18.09<br>20.09 | |
| 9 | Туры һәм кыек сөйләм турында гомуми мәгълүмат. | Сөйләмнең ике төрле: телдән һәм язма рәвештә булуы. Сөйләмне башкаручының сөйләүче яки автор дип аталуы. Үзгәртелмичә кулланылган чит сөйләмнең туры сөйләм дип, ә үзгәртелеп кулланылган чит сөйләмнең кыек сөйләм дип аталуы. Язма әсәрләрдән алынган туры сөйләмнең цитата дип аталуы. | 22.09 | |
| 10 | Туры сөйләм янында тыныш билгеләре. | Туры сөйләмнең куштырнаклар эченә алынуы. Туры сөйләм янында тыныш билгеләре куюның өч төргә бүленүе. | 25.09 | |
| 11 | Диалогта тыныш билгеләре | Диалогта һәр репликаның кызыл юлдан һәм сызык куеп язылуы | 27.09 | |
| 12-13 | Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү. | Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү үзенчәлекләре белән таныштыру | 29.09<br>02.10 | |
| 14-15 | Туры сөйләмле җөмләгә синтаксик анализ | Туры сөйләмле җөмләгә синтаксик анализ ясый белү | 04.10<br>06.10 | |
| 16-17 | БСҮ. Иҗади изложение “Синең әниең” | Иҗади фикер йөртү сәләтен үстерү максатында | 09.10<br>11.10<br>13.10 | |
| 18 | Изложениене сыйныфта | Хаталарны анализлау, бергәләп тикшерү максатында | 16.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тикшерү, хаталарны төзәтү | | | |
| 19-20 | Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. | Ике гади җөмләдән торган җөмләнең кушма жөмлә дип аталуы. | 18.10<br>20.10 | |
| 21 | Тезмә кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. | Үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмләнең тезмә кушма жөмлә дип аталуына төшендерү, теркәгечле тезмә кушма җөмлә , теркәгечсез тезмә кушма җөмлә төрләрен аңлату. | 23.10 | |
| 22 | Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмлә. | Кушма җөмләдәге гади җөмләләрне үзара бәйли торган тезүче теркәгечләр: *җыючы, каршы куючы, бүлүче* теркәгечләр булуы. | 25.10 | |
| 23 | Теркәгечле тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. | Теркәгечле тезмә кушма җөмлә эчендәге гади җөмләләрнең бер-берсеннән өтер белән аерылуы. | 27.10 | |
| 24 | Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. | Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдә, гади җөмләләрне аеру өчен, өч төрле билге куллану: өтер, нокталы өтер, сызык. | 06.11 | |
| 25 | Иярченле кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. | Үзара ияртү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган җөмләнең иярченле кушма җөмлә дип, ияреп килгәне – иярчен җөмлә, ә ияртеп килгәне баш җөмлә дип аталуы. | 08.11 | |
| 26 | Синтетик иярчен җөмлә. | Баш җөмләгә үзенең хәбәре составындагы чаралар ярдәмендә ияргән, шунлыктан аңа керешеп киткән җөмләнең синтетик иярчен җөмлә дип аталуы. | 10.11 | |
| 27 | Синтетик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре. | Синтетик иярчен җөмлә белән баш җөмлә арасына бер генә билге – бары тик өтер генә куелу. | 13.11 | |
| 28 | Аналитик иярчен җөмләләр. | Баш җөмләгә үзенең составында тормый торган чаралар ярдәмендә ияргән җөмләләрнең аналитик иярчен җөмлә дип аталуы. Аналитик иярчен җөмләләрнең баш җөмләгә мөнәсәбәтле сүзләр, теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр, күтәрү интонациясе белән бәйләнүе. | 15.11 | |
| 29 | Аналитик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре. | Баш җөмләгә парлы мөнәсәбәтле сүзләр һәм ияртүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнгән иярчен җөмләләр янында өтер куелу. Баш җөмләгә күтәрү паузасы белән бәйләнгән иярчен җөмлә алдыннан һәрвакыт ике нокта куелу. | 17.11 | |
| 30-31 | БСҮ. Контроль изложение “Бикмүш бабай” | Катлаулы план нигезендә эчтәлекне төгәл итеп бирү. | 20.11<br>22.11 | |
| 32 | Язма эштәге хаталарны төзәтү эше. | Хаталарны төзәтү, аларны булдырмау максатында | 24.11 | |
| 33 | Аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне кабатлау. | Аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрне аера белү. | 27.11 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 34 | Иярченле кушма җөмләләр синонимлыгы. | Синонимик иярченле кушма җөмләләрдә мәгънә, нигездә бер үк булуы, иярчен җөмләләрнең дә бер үк мәгънәле сорауга җавап бирүләре. | 29.11 | |
| 35 | Диктант “Кышкы юлда” | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 01.12 | |
| 36 | Язма эштәге хаталарны төзәтү эше. | Хаталарны төзәтү, аларны булдырмау максатында | 04.12 | |
| 37 | Иярчен җөмлә һәм аның мәгънә ягыннан төрләре. | Иярчен җөмләнең ия, хәбәр, хәл, аергыч җөмлә, тәмамлык җөмләләргә бүленүе. Иярчен хәл җөмләнең иярчен урын, иярчен вакыт, иярчен рәвеш, иярчен күләм, иярчен сәбәп, иярчен максат, иярчен шарт һәм иярчен кире җөмләләргә бүленүе. Тыныш билгеләренең куелышы. | 06.12 | |
| 38-39 | Иярчен ия һәм хәбәр җөмләләр. | Иярчен ия җөмләнең баш җөмләнең иясе урынына килүе һәм *кем? нәрсә?* сорауларына җавап бирүе.<br>Иярчен хәбәр җөмләнең баш җөмләнең хәбәре урынында килүе һәм *нинди? Нәрсә? Нәрсәдән? Кемгә? Күпме?* сорауларына җавап булуы. | 08.12<br>11.12 | |
| 40-41 | Иярчен тәмамлык һәм иярчен аергыч җөмләләр. | Иярчен тәмамлык җөмләнең баш җөмләнең тәмамлыгы урынында килүе һәм *кемне? нәрсәне? нәрсәгә? кемгә? кемнән? нәрсәдән? кемдә? нәрсәдә?* сорауларына җавап бирүе..<br>Иярчен аергыч җөмләнең баш җөмләнең аергычы урынында килүе һәм *нинди? кайсы? кемнең?* сорауларына җавап бирүе. | 13.12<br>15.12 | |
| 42 | Контроль диктант «Кышкы ял вакытында» | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 18.12 | |
| 43 | Язма эштәге хаталарны төзәтү эше. | Хаталарны төзәтү, аларны булдырмау максатында | 20.12 | |
| 44-45 | Иярчен вакыт һәм иярчен урын җөмләләр. | Иярчен вакыт җөмләнең баш җөмләдәге эш яки хәлнең вакытын белдерүе һәм кайчан? кайчаннан бирле? кайчанга чаклы? сорауларына җавап бирүе.<br>Иярчен урын җөмләнең баш җөмләдәге эш яки хәлнең урынын белдерүе һәм кайда? кайдан? кая? кебек сорауларга җавап булуы. | 22.12<br>08.01 | |
| 46 | Беркетмә язарга өйрәнү. | Эш кәгазьләре үрнәкләре белән танышуны дәвам итү | 10.01 | |
| 47-48 | Иярчен рәвеш һәм иярчен күләм җөмләләр. | Иярчен рәвеш җөмләнең, баш җөмләдәге эш яки хәлнен рәвешен белдерүе һәм *ничек? ни рәвешле?* кебек сорауларга җавап булуы.<br>Иярчен күләм җөмләнең баш җөмләдәге эш яки хәлнең күләмен белдерүе һәм *күпме? никадәр? ни дәрәҗәдә?* кебек сорауларга җавап булуы | 12.01<br>15.01 | |
| 49-50 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Изложение “Дуслар” | Катлаулы план нигезендә эчтәлекне төгәл итеп бирү. | 17.01<br>19.01 | |
| 51 | Язма эштәге хаталарны төзәтү эше. | Хаталарны төзәтү, аларны булдырмау максатында | 22.01 | |
| 52-53 | Иярчен сәбәп һәм иярчен | Иярчен сәбәп җөмләнең баш җөмләдәге эш яки хәлнең сәбәбен белдерүе һәм | 24.01 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | максат җөмләләр. | *ник? нилектән? ни сәбәпле? нәрсә аркасында?* кебек сорауларга җавап булуы. Иярчен максат җөмләнең баш җөмләдәге эш яки хәлнең максатын белдерүе һәм *ни өчен? нинди максат белән?* кебек сорауларга җавап булуы. | 26.01 | |
| 54-55 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Сочинение-хөкем йөртү. | Бәйләнешле сөйләм кнекмәләрен үстерү максатында | 29.01<br>31.01 | |
| 56 | Сочинениене сыйныфта тикшерү. Хаталарны анализлау, төзәтү эше. | Хаталарны төзәтү, аларны булдырмау максатында | 02.02 | |
| 57-58 | Иярчен шарт һәм иярчен кире җөмләләр. | Иярчен шарт җөмләнең баш җөмләдәге эш яки хәлнен үтәлү-үтәлмәвенә шарт булган эш яки хәлне белдерүе һәм *нишләсә? ни булса? нинди шартларда?* кебек сорауларга җавап булуы. белдерүе.<br>Иярчен кире җөмләнең көтелгән эш яки хәлнең баш җөмләдә киресе булачагын белдерүе һәм *нәрсә булса да? нәрсәгә карамастан?* сорауларына җавап булуы. | 05.02<br>07.02 | |
| 59-60 | Иярчен аныклагыч җөмләләр | Иярчен аныклагыч җөмләләрнең төзелеше ягыннан аналитк төре булуы. Иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче аналитик чаралар, тыныш билгеләре | 09.02<br>12.02 | |
| 61-64 | Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау. | Бүлек буенча өйрәнелгәннәрне ныгыту. Кушма җөмләләрне схемаларда күрсәтү күнекмәләре булдыру. Тыныш билгеләренең куелышы. | 14.02<br>16.02<br>19.02<br>21.02 | |
| 65 | Диктант(тикшерү диктанты) | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 23.02 | |
| 66 | Хаталарны анализлау, төзәтү эше. | Хаталарны төзәтү, аларны булдырмау максатында | 26.02 | |
| 67 | Катлаулы төзелмәләр турында төшенчә | Икедән артык грамматик нигезе булган җөмлә катлаулы төзелмә булуы | 28.02 | |
| 68 | Күп тезмәле катлаулы төзелмә | Үзара тезү юлы белән бәйләнгән катлаулы төзелмәнең күп тезмәле катлаулы төзелмә булуы Тыныш билгеләренең куелышы. | 02.03 | |
| 69 | Күп иярченле кушма җөмлә турында төшенчә. | Гади җөмләләрнең үзара ияртү юлы белән генә бәйләнгән катлаулы төзелмәнең күп иярченле кушма җөмлә дип аталуы. Тыныш билгеләренең куелышы | 05.03 | |
| 70 | Тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә. | Ике җөмләнең бер баш җөмләгә ияреп килеп, һәм ул җөмләләрнең икесе дә мәгънәләре буенча ике төргә караса, андый җөмләләрнең тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә дип аталулары. Тыныш билгеләренең куелышы | 09.03 | |
| 71 | Диктант (тикшерү диктанты) | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 12.03 | |
| 72-73 | Тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмлә. | Ике җөмләнең бер баш җөмләгә ияреп килеп, һәм ул җөмләләрнең икесе дә мәгънәләре буенча бер төргә караса, андый җөмләләрнең тиңдәш түгел иярүле | 14.03<br>16.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | күп иярченле кушма җөмлә дип аталулары**.** Тыныш билгеләренең куелышы | | |
| 74-75 | Бер-бер артлы иярүле күп иярченле кушма җөмлә. | Ике җөмләнең бер баш җөмләгә бер-бер артлы ияреп килүләренең бер-бер артлы иярүле күп иярченле кушма җөмлә дип аталулары. Тыныш билгеләренең куелышы | 19.03<br>21.03 | |
| 76-77 | Берничә төр иярүле күп иярченле кушма җөмлә. | Күп иярченле кушма җөмләдә җөмләләр үзара тиңдәш иярү, тиңдәш түгел иярү, бер-бер артлы иярү юлы белән (кимендә ике төрле бәйләнеш) бәйләнсәләр, мондый җөмләләрнең берничә төр иярүле күп иярченле кушма җөмлә дип аталулары. Тыныш билгеләренең куелышы | 23.03<br>04.04 | |
| 78-79 | Бәйләнешле сөйләм үстерү. Контроль изложение<br>” Хезмәткә – хөрмәт” | Катлаулы план нигезендә эчтәлекне төгәл итеп бирү. | 06.04<br>09.04 | |
| 80 | Хаталарны анализлау, төзәтү эше. | Хаталарны төзәтү, аларны булдырмау максатында | 11.04 | |
| 81-85 | Иярченле кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау. | Иярченле кушма җөмләләр буенча өйрәнелгәннәрне ныгыту. Кушма җөмләләрне схемаларда күрсәтү күнекмәләрен кабатлау, ныгыту. | 13.04<br>16.04<br>18.04<br>20.04<br>23.04 | |
| 86-87 | Контроль сочинение (сыйфатлама) | Сочинениегә материал туплау, аларны эзлекле тәртипкә китерү, язу, акка күчерү. | 25.04<br>27.04 | |
| 88 | Сочинениене бергәләп тикшерү, хаталарны төзәтү | Сочинениедәге хаталарны анализлау, төзәтү | 30.04 | |
| 89-94 | Катнаш кушма җөмлә. | Гади җөмләләре үзара тезү юлы белән дә, ияртү юлы белән дә бәйләнгән катлаулы төзелмәләрнең катнаш кушма җөмлә дип аталулары. Тыныш билгеләренең куелышы | 02.05<br>04.05<br>07.05<br>09.05<br>11.05<br>14.05 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 95-100 | Катлаулы төзелмәләрне кабатлау, синтаксик анализ ясау | Бүлек буенча өйрәнелгәннәрне ныгыту. Кушма җөмләләрне схемаларда күрсәтү күнекмәләре булдыру. | 16.05<br>18.05<br>21.05<br>21.05<br>23.05<br>23.05 | |
| 101-102 | Тезем. | Тиңдәш кисәкләре яки тиңдәш җөмләләре күп булу аркасында бик нык җәенкеләндерелгән гади яки кушма җөмләләрнең тезем дип аталулары. Тыныш билгеләренең куелышы | 25.05<br>25.05 | |
| 103 | Контроль диктант “Беренче яңгыр” | Грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | 28.05 | |
| 104-105 | Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре | Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләренең куелышы | 30.05<br>30.05 | |

**Укыту – методик комлекты**

| УМК | Укытучы өчен методик әдәбият | Укучылар өчен әдәбият |
|---|---|---|
| 1.Татар мәктәпләрендә балаларга татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты<br>**Программа:** Татар урта гомуми белем мәктәпләре өчен татар теленнән программа” (М.З.Зәкиев, К.З.Зиннәтуллина, С.М.Ибраһимов, Н.В.Максимов).<br>**Дәреслек:**<br>Зәкиев М.З. , Максимов Н.В. Татар теле: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы 8нче сыйныф. Казан, “Татарстан китап нәшрияты”, 2015. | 1.Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы (Ф.С.Вәлиев, Г.Р.Саттаров. – Казан. “Раннур”, 2000)<br>2.Хәзерге татар әдәби теле. (Ф.С.Сафиуллина, М.З.Зәкиев. Казан, “Мәгариф”, 2005)<br>3.Татар грамматикасы (Татарстан фәннәр академиясе, Мәскәү,”Инсан”, Казан “Фикер”,1999) | 2.Татар теленнән 222 тест/-Х.Сәлим.-Казан, “Яңалиф”, 2005.<br>4.Татар теленнән кагыйдәләр җыентыгы, Казан,2003.-Н.Гыймадиева, Р.Нуруллина<br>5.Татар телендә тыныш билгеләре,Казан ,1985.-Ф.С.Сафиуллина, С.М.Ибраһимов, Э.Вафин |